Әдәбият галиме С. Сафуанов Ф. Габдерәхим иҗатын ике чорга аера: а) 1980 еллар ахырына кадәрге чор; б) 1990–2000 еллар шигърияте [28, 341–342 б.]. Баштагы утыз еллык иҗат гомерендә шагыйрьгә үзенең шигырьләрен һәм поэмаларын Уфада башкорт телендә чыгарырга туры килә. Башкортстан китап нәшриятында «Йөрәк уты» (1971), «Җирдәге йолдызлар» (1975), «Анкетага кермәгән юллар» (1978), «Алтын туй» (1982), «Күңел күзе» (1985), «Гашыйклар, сезгә генә» (1988) дип аталган китаплары бер-бер артлы нәшер ителә. Шул ук вакытта шигырьләре «Казан утлары»да туган телендә һәрдаим дөнья күрә.

Туксанынчы еллардан башлап, Башкортстан китап нәшриятында татар телендә китаплар чыгаруга юл ачылгач, Ф. Габдерәхим иҗатының икенче чоры башлана. Бүгенге көнгә кадәр дәүләт нәшриятында аның «Кичер мине!..» (1996), «Синең белән мин» (2002), «Гөлләр кебек!» (2015), “Сине яратам” (2023) дип аталган күләмле шигъри җыентыклары нәшер ителә. Болардан тыш шагыйрьнең шәхси нәшриятларда үзнәшер ысулы белән чыгарылган берничә китабы да бар.

Ф. Габдерәхим шигърияте галимнәр һәм тәнкыйтьчеләрдә зур кызыксыну уята. Тәнкыйтьче С. Сафуанов Ф. Габдерәхим лирик героеның шагыйрь шәхесеннән аерылмавын ассызыклый [28, 341 б.]. Әдәбият галиме К. Дәүләтшин шагыйрьнең шартлы-романтик фикерләү сыйфатын башкалардан аерып күрсәтә. [23, 57 б.]. Әлеге караш, тәнкыйтьче-галим М. Мөлеков тарафыннан да хупланып, шагыйрь иҗатының асылда логик образларга корылуы әйтелә [32, 29 б.]. К. Дәүләтшин шагыйрьнең индивидуаль стиле турындагы карашларын дәвам итеп, аның шигъриятендә фикер һәм хиснең бердәмлеген билгели: «Фәрит Габдерәхим иҗатында еш кына фикер образдан туа, ягъни җанлы образ бай фикергә нигез буларак гәүдәләнә. Бу исә – поэтик талант билгесе» [23, 57 б.]. Шуңа нигезләнеп, шагыйрьнең образлы фикерләү тибы сәнгатьчел-аналитик дип нәтиҗә ясала [23, 57 б.]. Дәлил итеп «Сагындыра» (1968) шигыреннән өзек китерелә: «*Биеклектән тау да масаймый бит, / И беркатлы гамьсез сабыйлык! / Инде күптән бәлигъ булып җиттем, / Ярсуларга хуҗа сабырлык.* ...Күренә ки, – ди К. Дәүләтшин, – строфадагы беренче тезмәдә символик мәгънәле афористик фикер, икенче тезмәдә гомер фасылына тойгылы бәя, соңгы тезмәләрдә лирик “мин”нең үзенә кагылышлы аналитик мөнәсәбәт, кыскасы, хис бөркелгән аналитик шигырьгә хас сыйфатлар ачык чагылган» [23, 58 б.].

С. Сафуанов билгеләгән аклык-сафлык үрнәге шагыйрьнең башлангыч чор иҗатында Туган җир һәм анда яшәүче кешеләр гәүдәләнешендә чагыла. «Ятсынмыйлар күркәм тупылларым...» (1960), «Җир бәйрәме» (1965), «Юл белмим диеп торма син» (1975), «Кандракүлдә» (1970), «Авылым – Арсланым» (1986) кебек шигырьләрендә Фәрит Габдерәхим аларны романтик күтәренкелек белән тасвирлый. Шунысы мөһим: иҗат тәҗрибәсе зураю белән, шагыйрь поэзиясендә туган җир образының гәүдәләнеше үзгәрә. Аның шигъриятендә фәлсәфи-әхлакый эчтәлекле Туган җир – газиз Әнкәй параллеле барлыкка килә:

| | |
|---|---|
| *Туган җирнең бөтен бизәкләрен<br>Чагылдыра минем Әнкәем!<br>Әнкәй сыны – туган җирем сыны...* [6, 28–29 б.] («Әнкәй сыны», 1985) | *Кичерәдер мондый чакта<br>Тик әнкәйләр, туган яклар.* [6, 24–25 б.] («Әниләр һәм туган яклар», 1970). |

Шагыйрь иҗатында ул фикри-мәгънәви яктан тагын да тирәнәйтелеп, *Табигать – газиз Ана* образына үстерелә:

*Бәлки давыл тынар җанда,*
*Сызылып таң ата инде.*
*Әниләрне,*
*Башка исем тап дисәләр,*
*«Кояш!» дип атар идем.* [6, 30–31 б.] («Кояш», 1972)

Шулай итеп, *хәтер, ана, туган як табигате* образлары Ф. Габдерәхим поэзиясендәге дөнья моделен шактый тулы күзалларга мөмкинлек бирә. Дөрес, ул да замана баласы булып кала, чор идеологиясен «җимереп чыкмый». Әмма иҗатының икенче чорында миллилек, татар халкының үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге турында гамьнәр аның шигъриятенең төп мәсләгенә әверелә.

Башкортстандагы татар поэзиясенең күренекле вәкиле Рим Идиятуллин бик соңлап танылa. Аның «Хәерле иртә» дигән беренче җыентыгы 1983 елда Уфада башкорт телендә дөнья күрсә, ә икенче «Хәерле көн» китабы, 14 ел узгач кына, 1997 елда Башкортстан китап нәшриятында татар телендә басылып чыга. 2007 елда Р. Миңнуллин аның шигъри әсәрләрен туплап, «Хәерле кич!» исеме белән Казанда Татарстан китап нәшриятында бастырып чыгара. 2017 елда исә шунда ук шагыйрьнең «Хәерле төн!» дип аталган шигъри тупланмасы нәшер ителә.

Шигырьләре вакытлы матбугатта, күмәк җыентыкларда пәйда булу белән үк, Р. Идиятуллин үзен кабатланмас каләм остасы буларак раслый. Н. Нәҗми Р. Идиятуллин шигъриятенең байлыгын, шагыйрьнең тирән фикерләү сәләтен, шигъриятттә иң төп аргумент саналган йөрәк януы белән тирән һәм каршылыклы хисләрен укучыга җиткерү осталыгын билгели [3, 71 б.]. К. Дәүләтшин шагыйрь әсәрләренең укучыга эмоциональ тәэсир итү көчен сүз ярдәмендә картина тудыру осталыгы белән сәбәпле бәйләнештә карый һәм аны буяулар белән эш итүче рәссамга тиңли: «Рим Идиятуллинның шигъри рәсем-картина иҗат итү осталыгы, гаять үзенчәлекле рәссам сәләтенә ия булуы сокландыра» [22, 35 б.]. Ул үз фикеренә дәлил итеп шагыйрьнең «Сукыр» дигән әсәрен китерә:

| | |
|---|---|
| *Җир тәненә*<br>*Суга да ул*<br>*Таягы белән,* | *«Авырттымы?» дигән кебек*<br>*Сыйпап уза*<br>*Табаны белән* [7, 23 б.]. |

Галимнәр билгеләгәнчә, Р. Идиятуллин стиленә гадәти, гади генә саналган хәл-күренешнең рәсемен тасвирлау аша яшәешнең тирән драматизмын ачып салу сыйфаты хас. Бу үзенчәлек аның тәүге тәҗрибәләрендә үк сиземләнә: *Сугыш бетте; / Ә малайлар һаман, / Матчадагы талчыбыкка карап, / «Усал» этиләрен көтте* [7, 21 б.]. Сүз ярдәмендә тудырылган сурәттә этиләре сугыш кырында мәңгелеккә ятып калган малайларның тирән фаҗигасе тасвирлана.

Алга таба Р. Идиятуллин шигъри дөньясы халык авыз иҗаты традицияләре, традицион фольклор образлары аша заман чынбарлыгын, чор проблемаларын ачу сыйфаты белән байый. Ул «Толлар урамында» циклындагы «Гөлҗамалның каладагы бер иртәсе» шигырендә ачык гәүдәләнә: *«Китә-әү...» Тукта, көйләр көйләгәнче, / Ипи-тозын чемчим иң башта; / Казлар, бәлкем, очып кайткандыр да, / Кызым калды ерак Донбасста...* [7, 114 б.].

Заманында ир-егетләр туган авылларын ташлап, «бәхет кошы» артыннан чит якларга чыгып киткәннәр, һәм, беркадәр байлык, акча туплап, туган якларына, сөйгән ярлары, газиз ата-аналары янына кайтканнар. Гаилә корып, балалар үстереп, нәсел-ыруны дәвам иткәннәр. Р. Фәхретдинов, Г. Исхакый тарафыннан «милләт анасы» буларак бәяләнгән хатын-кызлар бүген «Донбасска китүче каз» хәлендә: алар күңел җылыларын да, сөю-назларын да күбрәк чит милләт вәкилләренә бүләк итәләр, аларга балалар үстерәләр. «Донбасска очкан» кызлар «...беркайчан да үз тамырларына, үз теленә, үз халкына әйләнеп кайтмаячак... Казлар киткән җирләреннән очып әйләнеп кайтса да... Кызлары белән бергә милләт тә Мәңгелек чоңгылында югала... Шушы фаҗигане күңелләрне тетрәндерерлек итеп нибары дүрт юлга сыйдырган шагыйрь!» [33, 126 б.]. Халык авыз иҗаты традицияләрен иҗади үстереп, кыз һәм каз параллеле аша автор бүгенге көннең милли фаҗигасенә үз мөнәсәбәтен белдерә, аңа борчыла.

Р. Идиятуллин белән бер дәвердә иҗат итә башласа да, хаксыз рәвештә игътибарсыз калган Рәшит Гатауллин икенче буынның бер вәкиле булып тора. Аның тәүге шигырьләре 1968 елда «Беренче карлыгачлар»да Зөлфәт, М. Әгъләмовлар әсәрләре белән бергә дөнья күрсә дә, «Сагышлы моңнар» дип аталган бердәнбер җыентыгы, шагыйрьнең үлеменнән соң, бертуганнары Рәфит һәм Рәдиф Гатауллиннар тырышлыгы һәм Р. Миңнуллинның кереш сүзе белән Татарстан китап нәшриятында басылып чыкты.

Р. Гатауллинның беренче шигырьләре яшьлек романтикасы, берникадәр самимилеге, дөньяны үзенчәлекле сурәтләү осталыгы белән характерлана. Гомумән, шагыйрь әсәрләре «темалары белән дә, стильләре, формалары белән дә бер-берсен кабатламый» [8, 8 б.] Җәй

көне» шигырендә ул җәй фасылын, һич көтелмәгәнчә, әнисе белән чагыштыра:

| | |
|---|---|
| *Көзләре көз түгел,*<br>*Язлары яз түгел.*<br>*Җәй генә охшаган.*<br>*Яшелдән ясанган,* | *Эсседән сусаган, –*<br>*Әле генә эштән кайткан*<br>*Әнигә охшаган* [8, 15 б.]. |

Р. Миңнуллин ассызыклаган индивидуальлек, шагыйрь рухи мирасын вакыт агышында тикшергәндә, аеруча ачык күренә: 1960 еллар шигъриятендә романтик күтәренкелек, мәхәббәт хисләре өстенлек итсә, 1970 елларда алар фани дөнья, яшәеш мәсьәләләре белән бергә үрелеп бирелә башлый; милләт, ил язмышы мотивлары 1980 еллар иҗатының үзәгендә ята. Ә туган як – Башкортстан темасы Р. Гатауллин иҗатының лейтмотивы булып тора. Шагыйрь күңелендә Туган җиргә мәхәббәт хисе белән Казанга тартылу хисенең көрәшен К. Дәүләтшин бик оста тотып алган: «Башкортстанда яшәүче татарлар арасыннан әдәби омтылышы белән мавыккан кешегә, гадәттә, катлаулы дилемманы чишәргә туры килә, чөнки ул ике юл чатында торып кала. Әгәр аңарда “туган җир тойгысы” көчлерәк икән, ул илендә иҗат итә, ләкин аны Казан тарта – Тукай рухы чакыра. Шуңа да:

| | |
|---|---|
| *...Шул Марстан, шул Сәеттән үтеп,*<br>*Хәзер инде кая барасың?*<br>*Уфа – Казан... Гомер буе сызлар*<br>*Йөрәктәге олы яра син,*<br>*Уфаларда ятим итсәләр дә,*<br>*Казанда соң мине кем көтә?* | *Тукай рухы, Сибгат, Туфан рухы*<br>*Гомер буе шулар җилкетә...*<br>Әйе:<br>*Казаннарга барсам, Казан мине*<br>*Үги итмәс иде, чит итмәс.*<br>Ләкин:<br>*Чәрмәсәнем, Кармасаным гына*<br>*Ничек ташар икән мин киткәч,* |

ди Кушнаренко районы Марс авылы егете Рәшит Гатауллин» [22, 10–11 б.].

Остазы Н. Нәҗми иҗатындагы кебек үк, шагыйрь өчен дә туган җир, Ватан төшенчәсе туган тел төшенчәсенә тәңгәл килә, алар янәшә куела. Р. Гатауллин поэзиясендәге «үз җиреңнең үги баласы» итеп тоюдан килеп чыккан рухи дисгармония турыдан-туры туган тел язмышы белән бәйле: *...Бүлешергә мөмкин җирне, суны, / Илне мөмкин тартып алырга. / Йортсыз-җирсез торырга да була, / Тик язмасын телсез калырга* [8, 200 б.] («И туган тел»).

Р. Гатауллин 1960 – 1980 еллар иҗатында катлаулы эволюция кичерә: башлангыч чорда язылган шигырьләрендәге романтизм иҗат юнәлешеннән ул кырыс реализм позициясенә күчә. Бу күчеш-метаморфозалар шигъри әсәрләренең тематикасында, идея-эстетик эчтәлегендә, образлар системасында чагыла. Фикри һәм сәнгати күчештә чор иҗтимагый-сәяси вәзгыяте зур роль уйный.

Иҗат юлын 1970 елларда Башкортстанда башлап, төбәктәге яңа чор татар поэзиясенә нигез салучыларның тагын берсе – үзенчәлекле шагыйрә Халисә Мөдәррисова. «Халисә Мөдәррисова шигърияткә утлы һәм давыллы йөрәге белән килде. <…>. Шагыйрәнең шигырьләре, чын шагыйрьләргә хас булганча, эчке каршылыклар белән тулы, ә бу каршылыклар бик тә саллы һәм оригиналь поэтик образлар аша гәүдәләнә» [9, 12–13 б.]. Татарстанның халык шагыйре Р. Гаташ та бу иҗат әһеле каләменең индивидуальлеген күрсәтә [10, 8 б.]. И. Ихсанова Х. Мөдәррисованың «Баланнар» шигырен шушы ноктадан бәяләп, «кып-кызыл балан тәлгәшләре» символының аерылу-өзелү мәгънәсен белдерүгә хезмәт итүен яза [40].

| | |
|---|---|
| *Йөрәк төсле кызыл балан,*<br>*Каерып сындыралар.*<br>*..................................*<br>*Буш хыяллар коела ул,* | *Аларны сындырмаслар.*<br>*Балан төсле күңел була,*<br>*Аларны тындырмаслар...* [11, 6 б.]. |

Шагыйрә иҗатында балан образының мәгънәви вариацияләре С. Сафуанов тарафыннан билгеләнә: «Бер шигырьдә ул – инде җиткән, хәзерге вәхши заманыбызда явыз куллар тарафыннан пычратылу куркынычы алдында калган кыз булып күз алдына баса, икенчесендә тәү кат яры үпкән сылу кызны хәтерләтә, өченчесендә – куаклыкта кызарган балан “кан сарган яңа яра кебек”» [28, 364 б.].

Х. Мөдәррисованың бер төркем әсәрләрендә хатын-кыз тормышта, мәхәббәттә бөек зат, хәтта тынычлык, иминлек сакчысы буларак сурәтләнә. Шагыйрә лирикасы гомумкешелек мотивлар белән генә чикләнми, аның 1980 еллар поэзиясендә иҗтимагый-сәяси мотивлар калкулана. «Туган җирдәге илле илсезлек, телле телсезлек» мотивы лирик герой драматик кичерешләренең сәбәбен билгели: *Сөекле зат булалмадым Синдә, / Ни кылсам да, күңел кителде, / Үз өендә үги ана белән / Үсеп килгән бала шикелле* [10, 90 б.].

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк: икенче буын шагыйрьләре иҗатындагы социаль-сәяси мотивлар тагын да үстерелеп, иҗтимагый күренеш төсен ала, ике республика җитәкчелеген Башкортстан татарларының рухи-мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен конкрет гамәлләр кыла башлауга этәргеч бирә.

1980 еллар ахырында Башкортстанда башланган татар милли хәрәкәте төбәк татар шигърияте барышына да йогынты ясаган уңай нәтиҗәләргә китерә. «1991 елда дәүләт хисабына – "Өмет" яшьләр газетасы, 1994 елда "Тулпар" әдәби-нәфис журналы чыга башлады. Аның битләрендә канат ныгыткан авторлар бүген Башкортстандагы татар әдәби барышының әйдәп баручы көчләрен тәшкил итә» [34, 65 б.]. 1993 елда Башкортстан Республикасының татар телле язучылар берлеге оеша. 1994 елның 10 апрелендә аның I съезды уза. Җыенда оешманың идарәсе сайлана. Рәис вазифасы филология фәннәре докторы, профессор Рәиф Әмировка йөкләнә. 2000 елның 1 гыйнварына оешмада 35 әгъза исәпләнә [41, 89 б.]. 1993 елның октябрь–ноябрь айларында Башкортстан Язучылар союзында татар телле язучыларның рәсми иҗади берләшмәсе оештырыла. Берләшмәнең Нәҗип Асанбаев, Марат Кәримов, Азат Магазов, Таһир Таһиров, Мөкәррәмә Садыйкова, Суфиян Сафуанов кебек тәҗрибәле әдипләрдән торган ун кешелек бюросы сайлана. Берләшмәнең беренче җитәкчесе итеп шагыйрь Равил Шаммас тәгаенләнә. 1995 елдан 2000 еллар башына кадәр бу вазифаны шагыйрь Муса Сираҗи башкара [42, 357 б.].

1994 ел башында Башкортстан «Китап» нәшриятында «Башкортстан халыклары әдәбияты секторы» оештырыла. Нигездә, ул татар телендәге матур әдәбият, дәреслекләр һәм уку кулланмалары чыгару белән шөгыльләнә. 1994 елның 3 февралендә сектор әзерләгән беренче китап – Марис Назировның татар телендәге «Янә утларга керәм» [12] җыентыгы басылып чыга [43, 16–17 б.]. Ул вакытта Башкортстан Язучылар берлеген җитәкләгән шагыйрь һәм галим Равил Бикбаев 1994–1996 еллар аралыгында нәшриятта татар телендә 8 шигырь китабы дөнья күрүен билгели [42, 349 б.]. 1994–2005 елларда барлыгы «татар телендә 133 басма, шул исәптән 97 әдәби китап һәм 36 дәреслек нәшер ителә» [44, 57 б.]. «2016 ел башына әлеге нәшриятта татар телендә барлыгы 210 китап басылып, шуларның 115е – шигърият, 83е проза жанрларына карый. Шул исәптән, сектор оештырылгач, 1994 елдан алып бүгенге көнгә кадәр төрле әдәби жанрларны берләштергән 12 җыентык та татар телендә басылып чыккан» [34, 66 б.]. Әлеге сыйфади үзгәрешләр 1990 еллар уртасына Башкортстанда үз моңы, үз аһәңе, үзенчәлекле сыйфатлары булган татар шигърияте формалашуга китерә.

«Нинди генә әдәбиятны алып карамыйк, аның нигезендә халык мәнфәгатен алга кую – тормыш-көнкүрешен яктырту, рухи дөньясын, язмышын кайгырту, проблемаларны гомумкешелек кыйммәтләре яктылыгында чишәргә омтылу ята» [2, 104 б.], – дип яза Л. Ваһапова. Алар 1990 елларда Башкортстандагы татар шигъриятенең үзәген билгели. М. Нәзировның туган җир, Ватан тойгысын гәүдәләндергән шигырьләренең стиле гадилеге, самими җылылыгы, поэтик сурәтнең ихласлыгы белән аерылып тора [22, 77 б.]. Тикшеренүчеләр хезмәтләрендә М. Нәзировның беренче шигырьләрендә үк күзәтелгән туган җир, туган тел мотивларының үзәктә торуы билгеләнә. Алар М. Нәзиров шигъриятенең лирик герой кичерешләре палитрасын баетудан тыш, шагыйрь тормышына да йогынты ясый, «шагыйрь бу тойгыларның кайсы да булса берсен алдын күреп, икенчесенә хыянәт итә алмады. Нәтиҗәдә ул да озак еллар "Кызыл таң" гәзитенең генә шагыйре булып кала килде. Казан өчен ул – Башкортстан әдибе, ә башкорт әдәбияты дөньясы өчен – татар шагыйре булып исәпләнде» [29, 4 б.].

Шагыйрь күңелендәге туган җир тойгысы белән татар теле һәм әдәбиятының үзәге булган Казанга омтылу теләге арасында барган көрәш М. Нәзировның «Йорт казлары» [12, 36–37 б.] шигырендә аеруча калку һәм образлы гәүдәләнеш таба. Шагыйрьнең драматик кичерешләре антитеза алымы ярдәмендә тирәнәйтелә: «канатларны көчле кагып», «җырлап», «әллә кайларга» очкан ирекле кыр казларына, алар артыннан омтылып, «канатканчы канат кагып», «чабып» йөргән йорт казлары каршы куела:

| | |
|---|---|
| *Омтылганда болытларга,*<br>*Бәреләләр кыекларга.*<br>*Кереш чөйгән таш-ук сыман*<br>*Төшү белән килеп җиргә,*<br>*Каурыйларын чәчеп җилгә,* | *Ыңгырашып, сыкрап, елап,*<br>*Ярсып, соңгы көчне җыйнап:*<br>*Каңгылдыйлар:*<br>*Кыйгак-кыйгак...* [12, 36–37 б.] |

Әдәбият галиме Р. Әмиров карашынча, бу әсәрдә «киек казлар дөньясы – күкләр, җырлар,

киңлек һәм горур тынычлык; йорт казларының мохите – җир, чикләре – йорт-кура, моңнары – ярсу-үксү, аһ-зар. Әмма <…> бу ике дөнья бер-берсенә каршы куелмый, үзара чәкәштерелми, чөнки мәгънә эчтәлеге башка булса да – тавышлар бер, тәгаенләнеше белән аерылса да – канатлар бер. Тик лирик геройның күңеле генә, романтик омтылулар янынннан үтеп, йорт казларына табан юл ала» [30, 99 б.] Әсәрдә кыр казлары һәм йорт казлары янәшәлеге ярдәмендә шагыйрь ясалма чикләр аркасында икегә бүленгән татар дөньясын, Башкортстанда яшәүче татарларның рухи фаҗигасен, үзенең күңел драмасын тетрәндергеч итеп, образлы сынландыруга ирешә. Шигырьнең соңгы строфасы моны укучыга бар тулылыгы белән ачып сала: *Казлар, казлар, аңлыйм сезне, / Мин кушылам сезнең зарга. / Очмыйча син түзеп кара / Иңнәреңдә канат барда. /...Яшәп кара* [12, 36–37 б.] «Марис Нәзиров шигырендәге коллизия, <…> мәдәни-әдәби тормышта урын алып, халкыбызның рухи үсешен тышаулап торган бер җитди социаль күренешкә беренчеләрдән булып ишарә ясый» [30, 100 б.].

Гадилектән катлаулыга бару, фәлсәфилек М. Закиров иҗатының бер үзенчәлеге булып тора [2, 104 б.]. Л. Ваһапова фикере шагыйрь-нең каләмдәше Р. Тимершин тарафыннан ныгытыла: «Башкалар күрмәгәнне күрү һәм гади генә күренештән көтелмәгән фәлсәфи фикер чыгару – шагыйрьнең осталыгы» [13, 4 б.]. Символик образга төрелеп бирелгән фәлфсәфи фикер тирәнлеген М. Закировның ике юллык «Шагыйрь» шигыре ачык дәлилли: «*Әле кабере юк, / шуңа кадере юк*» [45, 16 б.]. Әлеге икеюллык халык шагыйре Н. Нәҗми күңелендә зур эмоциональ кичерешләр тудыра.

М. Закировтагы фәлсәфи тирәнлек тормыш тәҗрибәсе, язмыш сынаулары белән бәйләнгән. Бик яшьли әтисез калу ачысы, балачактагы югалтулар, тормыш авырлыгы, хисләр киеренкелеге киләчәктә шагыйрь кулына каләм алырга этәрә. *Дүрт яшьтән үк әтисез бу дөнья, / Ахрысы, ул эзсез узмаган. / Мин дүрт яшьтән ятим, кырыгында / Ятим калганнарны кызганам* [13, 162 б.]. Бу тема шагыйрьнең «Авылдашка хат» поэмасында «шигърият – язмыш» параллеле. ярдәмендә тагын да үстерелә: *Нигә язам?.. Ә нигә язмаска?! / Бу гомерем башы, язмышым. / Шигырь язып була. Ә шигърият / Язмышлардан башка бармы соң?* [14, 108 б.]

Тәнкыйтьчеләр фикеренчә, «Мөхәммәт Закиров шигърияте гадилеге, халыкчанлыгы белән аерылып тора, <…> шагыйрь каләме күп очракта туган як, туган йорт, туган ил, туган тел кебек изге төшенчәләргә зур урын бирә. Әлеге төшенчәләрне М. Закиров Бөек Ана концепциясе аша ача» [2, 104 б.]. Поэтик образлылыкка шагыйрь Ана белән сөйләшү аша ирешә: *Нинди кайгыларың бар соң, әнкәй, / Үксетерлек сине төшемдә?* [13, 20 б.]. Шул рәвешле, яшәеш чыганагы, тормыш дәвамы, гомер һәм яшәү учагын саклаучы, яклаучы, туган җирнең тарту көче булган Ана образы туа. Анадан алган моңны, илаһи нурны кешеләргә өләшүче лирик герой бу очракта үткән белән киләчәкне тоташтыручы, буыннар бәйләнешен тәэмин итүче ролендә килә. М. Закиров шигъриятендә Ана образы туган ил, туган авыл образларыннан аерылгысыз. Автор, «Пәйгамбәрләр» [13, 27 б.] шигырендә ата-бабалардан калган рухи мирасны, тормыш тәҗрибәсен туплаган авыл картларының сафлары сирәгәя баруын күреп, аларны эңгердә югалган «пәйгамбәр»ләргә тиңли. «Югалтмагыз, авылдашлар» [13, 28 б.] шигырендә исә, үзе дә алар артыннан шушы эңгерләргә кереп, «каты бәгырьле» шәһәр чынбарлыгыннан котылырга тели. Тикшеренүчеләр билгеләвенчә, «әнә шул авыл гаме, җирле халыкның психологиясе, җор теле, фикер аныклыгына ия тезмәләр, бер-берсенә бәйләнеп, каләм иясенең иҗат концепциясен хасил итә» [46, 60 б.].

Әлеге буынның янә бер вәкиле – Салават Рәхмәтулла иҗаты 1990 еллар башыннан алып тәнкыйтьчеләрнең игътибар үзәгендә булды. Үткән белән бүгенгене, хакимият белән халыкны, авыл белән шәһәр мохитен каршы кую, күпләрнең яшәү рәвешенә әверелгән мал культы белән иҗатчының күңел азатлыгы каршылыгын образлы гәүдәләндерү шагыйрь шигъриятенең кабатланмас бер үзенчәлеге булып тора. «Салаватны Салават иткән сыйфат <…> – фәлсәфи караш, фикер тыгызлыгы, гади, аңлаешлы тел һәм җорлылык. Мин аны бу сыйфатлары өчен Такташ-Атнабай шигърияте – “бунтарь поэзия” вәкиле дип атар идем» [15, 197 б.]. – дип яза М. Вафин. А. Латыйпова шагыйрь иҗатындагы тормыш картинасының «авыл – шәһәр» бинар оппозициясенә нигезләнүен күрсәтә [47, 14 б.]. К. Дәүләтшин исә «Салават Рәхмәтулла поэтикасына гадилек, гадәтилек хас» булуын билгеләп, аның «иң катлаулы, баш җитмәслек тормышчан ситуацияләрне, җитди анализ сорый торган иҗтимагый мәсьәләләрне һәм аларга карата

тирән фәлсәфи бәяне укучы өчен мәгълүм булган хәл-күренешләр аша, замандашының тормыш тәҗрибәсенә таянып гәүдәләндерү» осталыгын күрсәтә [25, 45 б.].

*Иң авыры һаман алда булган: / Шагыйрь дигән исем күтәрдем,* [15, 57 б.] дип, С. Рәхмәтулла язучылык һөнәре, шагыйрьлек миссиясе, халык алдында җаваплылык, намуслылык хисе турында уйлана. Икенче бер шигырендә, шагыйрьгә салынган рухи йөкләмәнең зурлыгын Пушкин шәхесе аша ачып, болай дип яза: *...Бөек хисләр бөек калсын өчен, / Бөек Пушкин бара дуэльгә...* [15, 64 б.]. Гражданлык лирикасы үрнәкләрендә шагыйрь позициясенең ачыклыгы, гаделсезлекләргә мөнәсәбәт аныклыгы шагыйрь каләменең үзенчәлеген билгели: *Башка илдә – яшәү башка! / Безме ким башкалардан? / Патшалармы илдән уңмый? / Әллә ил – патшалардан?* Бу калыптагы әсәрләрдә халык, милләт, туган җир һәм кеше язмышы да әрнү-сагышлы кичерешләр аша яктыртыла: *Туган җирдә урыннар күп / Утырып уй уйлый торган... / Тәгәрәп елый торган...* [16, 71 б.]. Шагыйрь үз язмышын халык язмышыннан аермый, бөек Тукай традицияләрен дәвам итеп, аларны бербөтен итеп карый: *Халык тудырмаса –/ шагыйрь тумый, / Шагыйрь үлми – халык үлмәсә* [15, 14 б.]. Халыкчанлык, үзенең һәм әсәрләренең язмышын халкы язмышыннан аерып карамау, аның кайгы-шатлыклары белән яшәү шагыйрь шәхесенең бер үзенчәлеге булып тора.

Башкортстандагы татар поэзиясе 2000 елны, канатларын нygытып, буыннар алмашын тәэмин иткән, киләчәккә карап юл алган хәлдә каршылый. Югарыда бәяләнгән буын вәкилләре шигъриятенә хас сыйфатлар Мөнир Вафин, Марат Кәбиров, Лилия Сәгыйдуллина, Нәҗибә Әминева, Рафыйга Усманова һәм башкалар иҗатында тагы да үсеп, яңа сыйфатлар, яңа төсмерләр белән баеды һәм татар әдәбияты эчендәге «Башкортстандагы татар шигърияте» феноменының бүгенге көнгә кадәр үсешен тәэмин итә.

Талантлары яңа меңьеллыкта ачылган дүртенче буын шагыйрьләре арасында иҗатының муллыгы, идея-эстетик кыйммәте һәм образлылык ягыннан Н. Әминева шигърияте аерым урын алып тора. Башкорт шагыйрәсе Т. Карамышева Н. Әминеваның шәхсиятле өслүб үзенчәлеген билгеләп, болай дип яза: «Шагыйрә тотрыклы әдәби стильгә генә таянмый, үз стилен тудыра. Шуңа аның шигырьләрендә штамп, шаблон дигән нәрсә юк. Нәҗибәнең стилен аның фикер агымы үзе тудыра, шигъри формасы әйтер сүзенә яраклашып ярала. Ә бу исә күрер күзгә бик ташланып бармаган новаторлык орлыгын барлыкка китерә» [48, 73 б.].

Чәч толымы нәфис әдәбиятта хатын-кызның матурлык символы булып тора. Ә Н. Әминеваның «Толым турында хикәят» шигырендәге толым – бәхет, әнкәйләрнең кул җылысын саклаучы, үткәннәр белән киләчәкне тоташтыручы хатирәләр чылбырын тәшкил итә. Шагыйрәнең лирик герое, затлы бүрек астына сыймаган толымын кистереп, әнисе турындагы җылы хатирәләрдән мәхрүм калмас өчен, гомер буена гади шәл уранып йөри:

| | |
|---|---|
| *Их, бар иде*<br>*чәчкәйләрем язылу,*<br>*Әнкәй кулы тигәч.*<br>*Хәсрәтләрем басылу,*<br>*Чәчләремнән аның*<br>*кулы сөйгәч.*<br><br>*Их, шул чакта*<br>*Әнкәм кул җылысын*<br>*Чәчтә тоюларым!..* | *Чәчләремне әнкәй*<br>*толым-толым*<br>*Үреп куюлары!..*<br>*Шәл ябыныйм, әйдә,*<br>*Заманча ул бүрек,*<br>*Әйдә, киелмәсен.*<br>*Әнкәм кул җылысын*<br>*югалтмыймчы –*<br>*Бәхетем кимемәсен!..*<br>[17, 107–108 б.] |

Биредә толым – чәч образының мифологик мәгънәсе дә шагыйрә кичерешләрен, фәлсәфи гамьнәрен тирәнәйтүгә хезмәт итә. Күренекле фольклорчы В.Я. Пропп билгеләвенчә, борынгы җәмгыятьтә «чәч — җан я магик көч урыны. Чәчсез калу – көчне югалту» булып исәпләнгән [49, 41 б.]. Әлеге фикер башка галимнәр тарафыннан да куәтләнә ([50, 274 б.], [51, 211–212 б.], [52, 175 б.]) . Башкорт галиме М. Минһаҗетдинов карашынча, «чәчсез булу — ул изге мифик көчләрнең яклавыннан мәрхрүм булу дигән сүз, җаныңны явыз мифик көчләргә бирү дигән сүз» [51, 212 б.]. Шулай итеп, шагыйрә толым образының илаһи тирәнлегенә ишарәләп, аны үзгә бер биеклеккә күтәрә. Шигырьдәге чәч толымын югалту – бәхетен, ул гына да түгел, асылын, тамырлар белән бәйләнешен югалту мәгънәсен белдерүгә хезмәт итә башлый.

Беркатлылык – Н. Әминева каләменең матур үзенчәлеге. Бу сыйфат «Җирнең затлысы» шигырендә ачык чагыла: *Беркатлымын. / Язып яшим / Беркатлы шигырь* [17, 186 б.]. Тик бу беркатлылык гади түгел. Лирик герой бәхет китергән беркатлылык халәтен бары тик изге җир – туган авылында гына кичерә ала: *Беркатлы, тик затлы җирнең / Мин*

*беркатлысы!../ Үз беркатлысын кимсетми / Җирнең затлысы* [17, 187 б.]

Н. Әминева авыл мохитен бар тулылыгы, бар нечкәлекләре белән сурәтләүгә ирешә. Шунысын да әйтик: аның шигъриятендә авыл – шәһәр каршылыгы тасвирлана. Шагыйрәнең дөнья сурәтендә авыл беркатлы, самими дөньяны, рухи чисталыкны, яктылыкны гәүдәләндерсә, шәһәр катлаулы, караңгы мохитне, гамьсезлек илен символлаштыра: *Шәһәрендә шәһәр өе кебек / Катлы-катлы алар* [17, 186 б.].

Күренгәнчә, Н. Әминева иҗат иткән шигъри дөнья моделе чынбарлыкның үзе кебек күп төсле, күп буяулы хәлләрдән тора. Авторның лирик герое да бай хисләр гаммасында гәүдәләнә. Җыеп әйткәндә, Н. Әминева шигъриятендә заман кешесенең дөньяга, кешеләргә һәм, гомумән, чынбарлыкка булган җылы мөнәсәбәте, ышандырырлык, реаль детальләр ярдәмендә тасвирланган.

Лилия Сәгыйдуллинаның иҗаты, матбугатта басылган беренче шигырьләреннән үк, «йөрәк акылы» шигърияте – интеллектуаль лирика буларак бәяләнә ([53, 54 б.], [22, 7 б.]). Тирән фәлсәфә һәм миллилек синтезы поэзиясенең асылын билгели. Шагыйрә гасырлар дәвамында шайтан таягы (русчасы: татарник. – *И.Ф.*) кебек мең төрле афәтләрне җиңеп, тере калган халкының бүгенге вәзгыятьтә юкка чыгу мөмкинлеге турында борчыла: *Дәверләр аша үтәмен, / Өмет-дөлделдә җиләм: / ...Татарник кына калмасмы / Татар исеме белән?* [18, 31 б.]. Бу риторик сорауның сәбәбе дә ачык. Ахшам вакыты җиткәндә дә, йокыдан арынмаган татарда азан әйтерлек тә кеше калмаган. Шагыйрә Сәгыйть Рәмиевтән эпиграф итеп алган «Таң вакыты... Татар йоклый...» дигән юлларны иҗади үстереп, бу гафләт йокысының аянычлы нәтиҗәләрен экзистенциаль фәлсәфә яссылыгында сурәти: *Уянырга уйладыңмы? / Тик соңладың. Кояш батты. / Төшеңдә дә өнсез идең, / Өндә – телсез калдың, халкым.* [18, 31 б.]. Фани дөньяда яшәү-яшәмәү дилеммасына тиңләштерелгән «илле илсезлек, телле телсезлек» мотивы Л. Сәгыйдуллина лирикасында кызыл җеп булып сузыла:

| | |
|---|---|
| *Илле илсез,*<br>*Телле телсез*<br>*Без бу җирдә.*<br>*Хаклы хаксыз,*<br>*Җырлы җырсыз* | *Без бу илдә.*<br>*Барлы-юклы*<br>*Без бу җирдә...*<br>*Бармы, юкмы*<br>*Без бу илдә?* [18, 19–20 б.] |

Туган тел, милләт язмышы турында уйланулар шагыйрәне, ирексездән, вакыт, яшәү мәгънәсе турында тирән фәлсәфи фикерләргә этәрә. Тәнкыйтьче Г. Сәгыйтова карашынча, Л. Сәгыйдуллина, берәүне дә кабатламыйча, вакыт символының тирән мәгънәләрен таба, аны хәрәкәтчән, үтүчән дөнья белән янәшә, хәтта аңардан да өстен куя.

| | |
|---|---|
| *Безнең гомер –*<br>*су өстендә*<br>*күбек кенә.*<br>*Дәрья өчен*<br>*ул бары тик*<br>*куык кына.*<br>*Дулкын шуңа*<br>*йөртә аны*<br>*куып кына.* | *Җилләр исә*<br>*уйнаталар*<br>*көлеп кенә...*<br>*Ә аннан соң*<br>*хушлашалар*<br>*үбеп кенә...*<br>*Ә күбекләр*<br>*тора һаман*<br>*туып кына.* [18, 8–9 б.] |

Кеше гомеренең кыскалыгын автор су өстендәге күбек белән чагыштыра, дәрья – вакыт, дулкын – мизгелләр, җилләр – вакыйгалар. Вакыт – Алла, вакыт – мәңгелек. Шушы мәңгелектә кунак, мөсафир гына булган кеше, аның язмышы, яшәеше авторны тирән уйландыра [54, 30–31 б.].

Үзенчәлекле талант иясе Мөнир Вафин XX – XXI гасыр чикләрендә Башкортстан татар шигъриятенең үзәгендә тора. Ә. Атнабай аны: «Ул – шагыйрь! Башка беркемгә дә охшамаган шагыйрь!» [55], – дип замандашларыннан аерып куя. Шагыйрь лирикасына “композицион новеллизмга охшаш” художестволы алым хас, ягъни әсәр “көтелмәгән финал белән тәмамлана”» [26, 35 б.]. Һәм ул авторның «сурәтле фикерләвендә шактый үзенчәлекле урын алып тора, образлылык принципларының нигезендә ята. Нәтиҗәдә, уй-хис, кичереш, вакыйгалардагы көтелмәгәнлек элементы укучыны гаҗәпләндерә, сискәндерә. Уйланырга, хакыйкатьне тирәнрәк аңларга ярдәм итә» [26, 35 б.]. Татарстанның халык шагыйре И. Юзеев бу хосусиятне «йөрәкне сискәндерү» сыйфаты дип атый [19, 5 б.]. Шагыйрьнең «Каз өмәсе» [19, 25 б.], «Күршем бүген ауда булып кайтты...» [19, 41 б.], «Әле бары җәй уртасы гына» [19, 52 б.] шигырьләрендә тирән фәлсәфи, сискәндерүуяту көченә ия булган фикерләр белдерелә: «Кешеләр каз өмәсендә бәйрәм итәләр, һәр җирдә тантана, бәхетле йөзләр, ә «бәбкә көткән малай бәргәләнә, кар өстенә җылы кан тама». Куян атып кайткан аучы да куана, бәйрәм итә, ә «гомеренең секундларын сузып, соңгы куян чаба яланда». Табигатьтә бәйрәм – җәй

уртасы...Чәчәкләрнең яңа аткан чагы. Сандугачлар гына түгел, карга җырларлык чор. Ә бит, кайчан да булса шушы бәйрәмне ташлап, мәңгелеккә китәсе бар... Уйламас җирдән уйланырсың... [19, 5–6 б.]

К. Дәүләтшин гыйльми күзаллавында шагыйрь каләменең тагын бер сыйфаты күрсәтелә: «ул кеше кичерешләрендәге сизелер-сизелмәс нюанс төсмерләрен сурәтләүдән бигрәк, кырыс чынбарлыкны аналитик акыл аша үткәреп, кайнар хискә манчып чагылдыру приципларын алга сөрә. Шуңа да аның шигырьләрендә антитезалы сурәт калку» [22, 99 б.]. М. Вафин кискен контрастлылыкка нигезләнгән сурәткә еш һәм уңышлы мөрәҗәгать итә. Яшьлек-гүзәллек һәм картлык бинар оппозициясе тетрәндергеч мәгънә тудыра:

| | |
|---|---|
| *Су ташыйлар яшь киленнәр*<br>*Берсеннән-берсе сылу.*<br>*Бәхеттер ул – шундый көләч*<br>*Һәм шундый дәртле булу.* | *Тукта, кем ул өстерәлә*<br>*Ярты чиләк су белән?*<br>*...Тома сукыр әби кайта*<br>*Җанга таныш юл белән.* [19, 43 б.] |

Шагыйрьнең осталыгы шунда: тамчылар да сокланырлык яшьлек фонында гәүдәләнгән бичара, зәгыйфь, тома сукыр карчык образы укучыны фаҗигале уйлануларга этәрә.

Шагыйрә һәм галимә Л. Сәгыйдуллина М. Вафин иҗатының эпиклык сыйфатын билгели: «Шигырь һәм эпос иҗат елгасының капма-каршы ярларында яшиләр төсле. Әмма Мөнир, шул ике каршылыкны берләштереп, яңа бөтенлек барлыкка китерә алган. Монда эпос шигырь ярыннан, шигырь эпос ярыннан башлана, ахры» [56, 28 б.]. Бу хасият «Детдом» [20, 95–96 б.] шигырендә ачык гәүдәләнә. Беренче карашка, әсәрдә хәзерге җәмгыятькә хас гадәти бер күренеш тасвирлана, әмма ул шагыйрьнең яралы йөрәге аша үтеп, драматик хисләргә манчыла. Шул рәвешле ятим бала фаҗигасен сурәтләү тирәнлегенә ирешелә: *Детдом. / Рәшәткәле койма ярыгыннан / Карап тора бала. / Кыз бала.*

Алга таба М. Вафин саран сурәтләү чаралары белән баланың җанлы портретын укучы алдына бастыра: *Сары чәче / Дымлы күзләренә кереп, / Тозлы яшьләренә чылана.*

Кыз, күзләрен мөлдерәтеп, айлар-еллар буена әти-әнисен көтә. Урамда «ташкын халык», ләкин бала ялгыз, аның язмышына тирәлек битараф. Бала көтә...

*...Сулкылдавын беркем ишетмәде,*
*Бүген дә ул бәхетен тапмады.*
*Иртәгәгә зур ышаныч белән*
*Гарип курчак тоткан гөнаһсыз кыз*
*Кирпеч өйгә карый атлады...*

Шигырьдәге үзенчәлекле образлылык, вакыйга киеренкелеге, фаҗигалелек укучы күңелендә хисләр өермәсе кузгата. Шул рәвешле, эпик башлангыч шигърияттнең лирик асылы белән үрелеп китә. Гөнаһсыз кыз баланың гарип курчагы, ятимлектәге сабый чагы аның «гарип» киләчәгенә ишарә ясый һәм әсәрнең трагизмын көчәйтә.

Л. Сәгыйдуллина «Минор Мөнир: шагыйрь иҗатына бер караш» мәкаләсендә М. Вафин шигъриятенең маргинальлек сыйфатын ассызыклый. Галимә бу очракта «чиктәш», «язмышлар кисешкән зонада» яшәүне күз уңында тота [56, 29 б.]. Шагыйрьнең «Кыяфәтем, бәлки, шәһәрчәдер, ә йөрәгем һаман авылда» дигән шигъри юлларын Л. Сәгыйдуллина «социаль һәм рухи маргинальлекнең – чиктәшлекнең девиз-символы» [56, 29 б.] дип атый. «Тумышы һәм булмышы белән авылда калган, тормышы белән шәһәрне сайлаган, “буранда адашкан” йөз меңнәр язмышын, кичерешләрен чагылдыра шагыйрь. Ике арада бәргәләнә: авыл – кала, кала – авыл... “*Шыксыз димәс идем шәһәрне дә*”, – дип, шәһәрне дә якын итмәкче була. Ләкин бу очракта да икмәк комбинаты ягыннан искән, авылны хәтерләткән “*татлы җиле*” булганга, шәһәр җиле белән килешеп була икән. Авылның исә туфракка чумган тавыкларын да “һич түгелдер сөеп туймалы”» [21, 29 б.]: *Бәхетледер алар. / Ихатасы. Җиме. Кетәклек. / Ихатасыз, җимсез без мескеннең / Бер атнасы җиде китаплык* [21, 13–14 б.]

«Маргинальлекне шигъри “мин”нең авыллык белән шәһәрлек арасында каршылыклы бәрелешенә генә кайтарып калдыру дөрес булмас иде. Мөнир Вафин акыл һәм хис, тән һәм җан, туу һәм үлү, яшьлек һәм картлык, елау һәм елмаю арасында яши; шул ярларга үзен чиктәш итеп тоя» [56, 29 б.]. Шагыйрь иҗатындагы өченче төп үзенчәлек буларак «минор тональлекнең өстенлек итүе»н атарга кирәк, «үлем, картлык, ятимлек, ярлылык, ялгызлык... – һәр шигырьдә диярлек яши бу темалар» [56, 30 б.].

**Төп нәтиҗәләр**

1. 1950–2020 елларда Башкортстанда татар телендә язган шагыйрьләр иҗатын идея-эстетик эчтәлек, лирик герой, дөнья картинасы, шәхсиятле һәм төбәк өслүбе яссылыкларыннан

чыгып анализлау аларны дүрт буынга төркемләү мөмкинлеген бирә. Бу бүленешнең шартлылыгына карамастан, һәр буын үзенчәлекле сыйфатлар белән характерлана.

2. Беренче буынны Башкортстанның халык шагыйрьләре Н. Нәҗми һәм Ә. Атнабаев тәшкил итә. Алар үз язмышларын татар милләте язмышын белән тыгыз бәйләгән хәлдә, меңьеллык татар шигъриятенең поэтик традицияләренә нигезләнеп иҗат итә. Шагыйрьләр иҗатында беренче тапкыр киләчәктә Башкортстандагы татар шигърияте хәрәкәтендә «кызыл җеп» булып сузылачак «каршылык лирикасы» – татар теленең республикада һәм илдә кимсетелгән, «икенче сорт»лы хәлдә яшәвенә ачыну, моның белән килешмәү, сүз ярдәмендә каршы тору мотивлары калкып чыга һәм төбәк шигъриятендә дәвамчанлык принципларының берсен тәшкил итә.

3. 1960 елларда чынбарлыкны романтик буяуларда тасвирлаган Ф. Габдерәхим, Р. Идиятуллин, Р. Гатауллин һәм Х. Мөдәррисова икенче буын вәкилләре булып тора. 1980 елларның икенче яртысында илдәге иҗтимагый-сәяси вәзгыять тәэсирендә, алар иҗатындагы дөнья картинасы үзгәреп, кырыс реализмга хас үзенчәлекләр өстенлек итә башлый. Тормыштагы диалектик каршылыкларны художестволы ачу, аларны хәл итү юлларын эзләү иҗатларының төп мәсләгенә әверелә. Бу каршылыклар, нигездә, Башкортстан республикасында татар теленең статусы тудырган рухи дисгармония, канәгатьсезлек белән бәйле була. Бу буын шагыйрьләре иҗатында Туган ил образы Туган тел белән тәңгәлләштерелеп, әсәрләренә «илле илсезлек, телле телсезлек» мотивлары килеп керә.

4. Өченче буын шагыйрьләре – М. Нәзиров, М. Закиров, С. Рәхмәтулла иҗатында Башкортстандагы татар шигърияте, идея-эстетик эчтәлеге, юнәлешләре, әдәби төбәк стиле ягыннан тәмам формалашып җитеп, татар поэзиясе составында көчле бер агым булып формалаша дип нәтиҗә ясарга тулы нигез бар. Табигать культы, кырыс реализм һәм романтизм сыйфатлары синтезын үзендә чагылдырган экспрессив-лирик стиль, халыкчан, садә тел, чынбарлыкның динамик үсештә сурәтләнүе әлеге буын шигъриятенең төп үзенчәлекләрен билгели.

5. Дүртенче буынга караган шагыйрьләр – Н. Әминева, Л. Сәгыйдуллина, М. Вафин шигъри дөньялары стиль төрлелеге, фәлсәфилеге, ассоциатив эчтәлеге, метафораларга корылган булуы белән алдагы буыннардан аерылып тора. Әлеге авторлар купшы сүзләрны, эпитетларны саран гына куллана, шул ук вакытта кыска гына шигырьгә дә тирән фәлсәфи мәгънә салырга сәләтле. Аларның шигъри әсәрләре Көнчыгыш һәм Көнбатыш поэтик традицияләре синтезын чагылдыру белән бергә, татар халкының милли фольклорына, шигъриятенә нигезләнә. Бу поэтик образлар, мотивлар, сурәтләү чаралары күчемлелегендә үк күренә. Шул ук вакытта, нигездә, Башкортстандагы татар шигъриятенә хас «илле-илсезлек, телле-телсезлек» мотивы бу буында үз үсешенең иң югары ноктасына күтәрелә.

## Йомгак

Шуны әйтергә кирәк: Башкортстан җирлегендә сәләтле әдәби көчләр дә, рухи – мәдәни традицияләр дә бар. Шагыйрьләр, аларның иҗат юнәлешләре дә төрле булса да, аларның һәммәсен дә бер үк моң – татар моңы берләштерә. Бу моң Шәмсетдин Зәки, Акмулла, Дәрдемәнд, Шәехзадә Бабич, Сәгыйт Рәмиев, Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури иҗатларыннан юл алып, Атнабай, Н. Нәҗмиләр аша бүгенгә кадәр килеп җитте. Миллилек, тирән фәлсәфә, хис һәм фикер гармониясе – аның төп хасиятләредер. Әлбәттә, шагыйрьләребез жанр, тема-проблема, стиль үзенчәлеге, мәсьәләләр куелышы һәм хәл ителеше ягыннан төрле әсәрләр иҗат итә. Әмма барысын бергә туплаган, бер җепкә тезгән образлы фикер йөртү, яшәешкә үзенчәлекле караш аша үзгә бер дөнья моделе тудыру хосусияте бар. Җәмгыяви-сәяси җилләр аерым чорларда, иҗат көчләрен бер-берсеннән аерылырга мәҗбүр итсә дә, җирле шигърият бүленмәс татар халкының рухи-мәдәни байлыгы һәм казанышы булып тора.

**Әдәбият**

1. *Вафин М., Хафизов С.* Туган җир музасы: Башкортстанда яшәүче татар телле шагыйрьләр иҗаты турында «кырлы» өстәл // Тулпар. 2001. №1 (40). Б. 23–29.

2. *Ваһапова Л.* Башкортстандагы хәзерге татар әдәбияты // Чын мирас. 2013. №5 (17). Б. 103–110.

3. *Нәҗми Н.* Милли жаным: мәкаләләр, истәлекләр, хатлар, шигырьләр, поэма / идея авт. һәм төз. Р. Миңнуллин. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 479 б.

4. *Атнабаев Ә.* Шигырьләр, поэмалар. Уфа, 1993. 192 б.

5. Атнабай. Халык шагыйре. Уфа: Башкортстан Республикасы «Рухият» фонды, 2000. 400 б.

6. *Габдерәхим Ф.* Гөлләр кебек: шигырьләр. Уфа: Китап, 2015. 157 б.

7. *Идиятуллин Р.* Хәерле кич!: шигырьләр, кечкенә драмалар, хикәятләр / төз. һәм соңгы сүз авт. Р. Миңнуллин. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. 271 б.

8. *Гатауллин Р.* Сагышлы моңнар: шигырьләр / төз. Рәфит һәм Рәдиф Гатауллиннар; кереш сүз авт. Р. Миңнуллин. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. 223 б.

9. *Мөдәррисова Х.* Былтыргы көз: шигырьләр / кереш сүз авт. Н. Нәҗми. Уфа: Башкорт. кит. нәшр., 1995. 80 б.

10. *Мөдәррисова Х.* Шәмәхә төн: шигырьләр / кереш сүз авторы Р. Гаташ. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 126 б.

11. *Мөҙәррисова Х.* Көмөш даға: шиғырҙар. Өфө: Башҡорт. кит. нәшр., 1982. 157 б.

12. *Нәзиров М.* Янә утларга керәм: шигырьләр, җырлар, поэма. Уфа: Китап, 1994. 144 б.

13. *Закиров М.* Кылычка кунган сандугач: шигырьләр / кереш сүз авт. Р. Тимершин. Уфа: Китап, 2005. 176 б.

14. *Закиров М.* Үзе уңалган яра: шигырьләр. Уфа, 1992. 124 б.

15. *Рәхмәтулла С.* Уяну: шигырьләр, җырлар, поэмалар / соңгы сүз авт. М. Вафин. Уфа, 1993. 212 б.

16. *Рәхмәтулла С.* Сулар үргә акса да: шигырьләр, поэмалар, замана такмаклары, эпиграммалар, тәрҗемәләр. Уфа: Китап, 2001. 240 б

17. *Әминева Н.* Җитәкләдем таң җилен: шигырьләр, поэма, сценарийлар, әкиятләр. Уфа: Китап, 2011. 277 б.

18. *Сәгыйдуллина Л.* Мизгелләр йолдызлыгы: шигырьләр. Уфа: Китап, 2004. 112 б.

19. *Вафин М.* Дөнья – куласа: шигырьләр / кереш сүз авт. И. Юзеев. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 95 б.

20. *Вафин М.* Йөрәгем парәләре: шигырьләр. Уфа: Китап, 2007. 272 б.

21. *Вафин М.* Сүзләр чәчтем // Биш кыллы саз: шигырьләр. Уфа: Китап, 2001. Б. 3–110.

22. *Дәүләтшин К.С.* Туган як шигърияте. Индивидуаль стиль һәм поэтик образлылык мәсьәләләре: уку әсбабы. Уфа: Башкорт дәүләт ун-ты нәшр., 2002. 108 б.

23. *Дәүләтшин К.* «Матурлыкны табигатьнең бөек иҗатчысы – Кеше койган»: Фәрит Габдерәхим шигъриятендә дөнья картинасы // Тулпар. 2007. №6 (81). Б. 56–61.

24. *Дәүләтшин К. С.* Яннарында газиз затлар... // Марис Нәзиров шигърияте: шагыйрь иҗаты турында мәкаләләр / С. Сафуанов ред-дә. Уфа: Мәгърифәт, 2000. Б. 23–40.

25. *Дәүләтшин К.* «Гомер буе» шагыйрь «эзләнә»... // Тулпар. 2002. №1 (46). Б. 44–47.

26. *Дәүләтшин К.* Шагыйрь фәлсәфәсе // Тулпар. 1996. №1 (10). Б. 34–36.

27. *Сафуанов С.* «Шигырьләрем, сез бит йөрәк каным...» // Нәҗми Н. Милли җаным: мәкаләләр, истәлекләр, хатлар, шигырьләр, поэма / идея авт. һәм төз. Р. Миңнуллин. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. Б. 236–242.

28. *Сафуанов С.* Рухи күперләр. Уфа: Китап, 2006. 376 б.

29. *Сафуанов С.* Туган җир тойгысы, туган тел тойгысы // Марис Нәзиров шигърияте: шагыйрь иҗаты турында мәкаләләр / С. Сафуанов ред-дә. Уфа: Мәгърифәт, 2000. 3–10 б.

30. *Әмиров Р.* Иңнәрендә канат барда... // Марис Нәзиров шигърияте: шагыйрь иҗаты турында мәкаләләр / С. Сафуанов ред-дә. Уфа: Мәгърифәт, 2000. Б. 95–102 б.

31. *Хәйбрахманов Р.* Чикләр аша // Нәҗми Н. Милли җаным: мәкаләләр, истәлекләр, хатлар, шигырьләр, поэма / идея авт. һәм төз. Р. Миңнуллин. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. Б. 4–10.

32. *Мөлеков М.* «Керәм давыл уртасына...» // Тулпар. 1996. №6 (15). Б. 28–29.

33. *Фазлетдинов И.* Тетрәнүләр шигърияте // Казан утлары. 2010. №2. Б. 124–129.

34. *Фазлетдинов И.К.* Тәнкыйтьтә Башкортстандагы хәзерге татар поэзиясе // Tatarica. 2016. №2 (7). Б. 57–72.

35. *Габдерәхим Ф.* Кузгатмакчы булсаң халык күңелләрен... // Тулпар. 2006. №1 (70). Б. 54–55.

36. *Гаташ Р.* «Мин бер якты югарылык күрәм...» // Шәһри Казан. 1993. 27 февраль.

37. *Мөдәррисов М.* Атнабай (Нәшир сүзе) // Атнабай. Халык шагыйре. Уфа: Башкортстан Республикасы «Рухият» фонды, 2000. Б. 5–9.

38. *Нәжми Н.* Шағирҙың һөйләшеүе // Совет Башҡортостаны. 1959. 11 гыйнвар.

39. *Миңнуллин Р.* Атнабайны каршылагыз! // Беҙҙең Атнабай: шиғырҙар, мәҡәләләр, иҫтәлектәр / авт.–төҙ. Р.К. Әмиров. Өфө: Китап, 2018. Б. 126–130.

40. *Иксанова И.* Таңдай нурлы, кылдай нечкә күңел // Мәдәни җомга. 2018. 25 апрель.

41. Татар энциклопедия сүзлеге / баш мөхәррир М.Х. Хәсәнев; җаваплы мөхәррир Г.С. Сабирҗанов. Казан: ТР ФА Татар энциклопедиясе институты, 2002. 830 б.

42. *Бикбаев Р.* Яуаптарҙы бергә эҙләргә: республика яҙыусыларының XII съезында һөйләгән доклады // Судьба земли, дыхание времени. Ил яҙмышы, заман һулышы. Өфө: Китап, 2009. Б. 320–364.

43. *Морзакаева Д.* Милли китап: Зәйнәб Биишева исемендәге Башкортстан «Китап» нәшриятында милли басмалар нәшерләү һәм биредә дөнья күргән китаплар хакында. Уфа, 2012. 151 б.

44. *Морзакаева Д.* Исә Болгар җилләре... // Тулпар. 2006. №2 (71). Б. 56–59.

45. *Нәҗми Н.* Пушкинча, Тукайча... // Тулпар. 1998. №1 (22). Б. 16–17.

46. *Кәшфи Л.* «Кызыл таң» һәм заман әдәбияты / гыйльми мөх. Ф.К. Фәтхетдинов; кереш сүз авт. Т.Н. Галиуллин. Уфа: Кызыл таң, 2014. 300 б.

47. *Латыпова А.В.* Современная татарская поэзия Башкортостана: национальная картина мира и жанровая парадигма: автореф. дис. ... канд. филол. наук / ФГАОУ ВО «Казанский (Приволжский) федеральный университет». Казань, 2021. 24 с.

48. *Карамышева Т.* Һалмаҡ тәлгәштәр // Ағиҙел. 1986. № 3. Б. 72–74.

49. *Пропп В.Я.* Исторические корни волшебной сказки / вступ. статья В.И. Ереминой. 2-е изд. Л.: Издательство ЛГУ, 1986. 364 с.

50. Татар мифлары: ияләр, ышанулар, ырымнар, фаллар, им-томнар, сынамышлар, йолалар. Икенче китап / Г. Гыйльманов хикәяләвендә. Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. 432 б.

51. *Минһажетдинов М.Х.* Ҡәләмендә ҡөҙрәт бар: монография, әҙәби тәнҡит һәм башҡорт фольклористикаһына арналған хеҙмәттәр / баш һүҙ авт. Т.А. Килмөхәммәтов һәм Ә.М. Сөләймәнов. Өфө: Китап, 1995. 256 б.

52. *Турсунов Е.Д.* Генезис казахской бытовой сказки: в аспекте в связи с первобытным фольклором. Алма-Ата: Наука, 1973. 216 с.

53. *Гыйззәтуллина Г.* «Шигърият – аның өчен...» // Тулпар. 1998. №5 (26). Б. 54.

54. *Сәгыйтова Г.* Мизгелләрдән – Мәңгелеккә // Тулпар. 2005. №1 (64). Б. 30–31.

55. *Атнабай Ә.* Җирнең кендегенә басып, аптырап карап торам // Кызыл таң. 1995. 15 август.

56. *Сәгыйдуллина Л.* Минор Мөнир: шагыйрь иҗатына бер караш // Тулпар. 2004. №4 (61). Б. 28–30.

# ПРОБЛЕМА ПОКОЛЕНИЙ В ТАТАРСКОЙ ПОЭЗИИ БАШКОРТОСТАНА

**Ильдус Камилович Фазлутдинов,**
Уфимский университет науки и технологий,
Россия, 450076, г. Уфа, ул. Заки Валиди, д. 32,
fazlutdinov75@mail.ru.

В предлагаемой статье рассматривается проблема творческих поколений в татарской поэзии Башкортостана. Исходя из научно-хронологического и диахронного аспектов, в работе дается историко-литературоведческий анализ развития татарской поэзии Башкортостана со второй половины XX века до сегодняшнего дня; раскрываются причины возникновения такого феномена, как «двуязычная татарская литература», обусловленные в первую очередь изменениями в общественно-политической и культурной жизни республики, вытеснением татарского языка из литературной печати и книгоиздания в 1950–1980-х годах; изучается влияние данных событий на индивидуальный стиль поэтов. Опираясь на качественную научно-теоретическую базу, автор раскрывает особенности отображения действительности в творчестве местных литераторов и подчеркивает, что картина мира в сознании поэта является определяющей в формировании его индивидуального стиля. Исходя из этого, делается попытка выявления как особенностей индивидуального стиля каждого из мастеров пера, так и общего регионального стиля татарской поэзии Башкортостана. На этой основе автор выделяет четыре творческих поколения в развитии региональной татарской поэзии исследуемого периода. На основе анализа творческого метода, содержания и формы, основных мотивов в произведениях наиболее выдающихся поэтов, выявляются общие качества, присущие каждому творческому поколению. В статье подчеркивается, что по своей поэтической ценности, идейно-эстетическому содержанию татарская поэзия региона основана на тысячелетних традициях татарской поэзии.

**Ключевые слова:** поэзия, индивидуальный стиль, поколение, литературная критика, Башкортостан, творческий метод, поэтический образ